ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет ур., 13

СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР**
**22 март 2019 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№ 115**

**2016 нчы елнын 24 нче августындагы 34 нче номерлы Красносельский авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә Муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары», 2007 нче елның 2 нче мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турындагы» Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге муниципаль берәмлегендәге муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә, 2016 нчы елның 24 нче августындагы 34 нче номерлы Красносельский авыл җирлеге Советы карары белән расланган (2018 елның 24 нче сентябрендәге 95 нче номерлы, 2018 нче елның 21 нче декабрендәге 108 нче номерлы карарлары редакциясендә), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 14 нче статьяны:

а) тубәндәге эчтәлекле 1.1. өлеш өстәргә:

«1.1.Гражданин контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасына билгеләнә алмый, ә муниципаль хезмәткәр муниципаль берәмлек башлыгы белән якын туганлык яисә үзлеге булган очракта (ата-аналар, ир белән хатын, балалар, абый-энеләр, апа-сеңелләр, шулай ук ир белән хатыннын абый-энелэре, апа-сеңелләре, ата-аналарын балалары һәм балаларынын ир белән хатыннары) контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләп тора алмый.

б) түбәндәге эчтәлекле 3 нче өлеш өстәргә:

«3. Җитәкче булып торучы муниципаль хезмәткәр җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында мәнфәгатьләр конфликтын төшереп калдыру максатларында әлеге җирле үзидарә органының сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында күрсәтелгән вазыйфаны биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый.»;

1.2. 15 нче статьяның 1 нче пунктындагы 3 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы идарәсендә яисә коммерциягә карамаган оешма идарәсендә (сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан тыш; һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты тарафыннан төзелгән идарәдә беренчел профсоюз оешманың сайлану органында түләүсез нигездә катнашу; съездда (конференциядә) яисә гомуми җыелышта, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләрендә катнашу; күрсәтелгән коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси партиядән һәм һөнәри берлек органыннан, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органыннан тыш) бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында яки яллаучы (эш бирүче) вәкиле рөхсәте белән аларның идарә коллегиаль органнары составына керү, муниципаль хокукый актта билгеләнгән тәртип белән), идарә органнарында һәм гамәлгә куючысы (катнашучысы) муниципаль берәмлек булган оешманың ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтүдән тыш, муниципаль хокукый актлар нигезендә, муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючының яисә идарәнең муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган; федераль законнарда каралган башка очраклар;

2. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советының 2016 нчы елның 24 нче августындагы 34 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2018 нче елның 21 нче декабрендәге 108 нче номерлы карарының 1.1 пунктындагы «а» пунктчасын төшереп калдырырга.

3. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтта http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм халыкка җиткерелгән көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе
Красносельский авыл җирлеге Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин